СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ　　　　КАРАР

«30» июль, 2024 ел　　　Алабуга шәһәре　　　№ 365

Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2023 елның 15 декабрендәге 301 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Алабуга муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 83 һәм 86 статьяларга таянып, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2023 елның 15 декабрендәге 301 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

*1 өлештә:*

1 пунктта «3 205 867,5» саннарын «3 253 628,7» саннарына алмаштырырга;

2 пунктта «3 483 778,0» саннарын «3 643 507,0» саннарына алмаштырырга;

3 пунктта «277 910,5» саннарын «389 878,3» саннарына алмаштырырга;

*3 өлештә:*

1 нче кушымтаның «2024 елга район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2) 3 статьяда:

2 нче кушымтаның «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының фаразлана торган керемнәре күләме» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә.

3) 5 статьяда:

3 нче кушымтаның «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә;

4 нче кушымтаның «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (АМР муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә;

5 нче кушымтаның «2024 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (АМР муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә;

4) 10 статьяда:

1 пунктта: «460 706,2» саннарын «470 706,2» саннарына алмаштырырга;

9 нчы кушымтаның «2024 елга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә муниципаль учреждениеләрне карап тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә җирлекләр бюджетларыннан район бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» 1 нче таблицасындагы үзгәрешләр кертелә торган өлешен бәян итәргә.

5) 13 статьяда:

11 нче кушымтаның «2024 елга өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар күләме» таблицасында үзгәрешләр кертелә торган өлешен бәян итәргә;

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджетның икътисади үсеше, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка һәм туризмга ярдәм итү мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов